**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА СТЕПНООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423009, с. Степное Озеро, ул. Школьная, дом 23, телефон:8(84345) 4-63-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**БИ КҮЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

423009, Би Күле авылы, Мәктәп ур., 23 йорт, телефон:8(84345) 4-63-34

ОГРН 1021605352438,ОКПО 04312541, ОКАТО 92246880000,
ИНН/ КПП 1632001635/163201001,ОКТМО 92646480

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 17» октябрь 2025 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 29 октябрендә 14 сәгать 00 минутта М. Горький урамы буенча 13нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында М. Горький урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 29 октябрендә 11 сәгать 00 минутта Совет урамы буенча 14нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында Совет урамы буенча, Клуб урамы буенча, Илюткино авылындагы Җиңү урамы буенча яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Илюткино авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе халык җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар Җыенының этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Илюткино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан тыш 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Илюткино авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М. Шакирова